РЕШЕНИЕ....... .....................КАРАР

№ 1 16.12.2019

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Мурзиха авыл җирлегенең Токмаш торак пунктында уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 16 декабрендә 10.00 сәгатьтә уздырылган гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләреннән чыгып беркетмә төзелде.

«Яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Мурзиха авыл җирлегенең Токмаш торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 300 (өч йөз ) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә, 18 яшькә җиткән, гомуми авыру инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан һәм сугышчан хәрәкәтләр, күп балалы гаиләләр, югары һәм урта-махсус (урта-һөнәри) уку йортларының көндезге бүлек студентларыннан җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түләүләр күләме 150 сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә риза булу (булмау):

- Токмаш торак пункты, Кызыл гвардия урамына юл салу өчен вак таш сатып алу.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 26 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 14 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 14 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш, «тоткарланды» - 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыенытүбәндәгеләрне кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Мурзиха авыл җирлегенең Токмаш торак пункты гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «Яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Мурзиха авыл җирлегенең Токмаш торак пункты территориясендә һәр балигъ булган кешегә 300 (ике йөз ) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм гомуми авыру инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 150 ( йөз илле ) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә:

Токмаш торак пункты, Кызыл гвардия урамына юл салу өчен вак таш сатып алуга риза.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Мурзиха авыл җирлегенең Токмаш торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Мурзиха авыл җирлегенең Токмаш торак пункты гражданнар җыены Мурзиха авыл җирлегенең рәсми сайтында (мурзихинское.городелабуга.рф.) «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

«Новая Кама» газетасында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен игълан итәргә,

4. Әлеге карар Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

Мурзиха авыл җирлеге Башлыгы ________ И.Р.Гаделшин